**Итоговая контрольная работа ( диктант с грамматическим заданием)**
**в рамках промежуточной аттестации**
**по родному (татарскому) языку для 9 класса**

**Бала**

Самолет ераклашты. Лейтенант команда бирде булса кирәк, алда яткан кызылармеецлар ашыгып тора башладылар. Урыныннан кузгалды Зариф. Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды. Баланың берәр якын кешесен күрергә теләп, тирә-ягына каранды, ләкин якында һичкем барлыгы сизелми иде. Зариф, бик гаҗәпләнеп, янә балага карады; бала чыннан да ялгыз иде. Ул үзе биеклек кенә бер куак янына баскан, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап тора. Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган... Ләкин хәзер тынычланган, нинди хәлдә булуын оныткан, ахрысы, аяк астындагы җиләкләрне җыярга керешкән. Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары оеклар белән сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган, ахрысы. (151сүз) (Әмирхан Еники)

**Бирем.**
1. Кире сүз тәртибе күзәтелгән җөмләне табып язарга.

2. Тезмә кушма җөмләләрне табып, җөмлә чикләрен билгеләргә, схемасын сызарга.

3.Соңгы җөмләне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә.

Электронный документ передан через оператора ЭДО ЗАО "ТаксНет" Вс, 01 дек 2024 14:04:40 МСК
Идентификатор документа 383a112b-65cb-4b06-a4f9-5f4e1cc37554

Контроль диктантларны бәяләү

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталары булмаган эшкә<br>Искәрмә. Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм бер пунктуацион хаталы эшкә | «5» ле билгесе куела.<br><br>«5» ле билгесе куела ала. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>Искәрмә. 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4» ле билгесе куела.<br>«4» ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>Искәрмә. 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3» ле билгесе куела.<br><br>«3» ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2» ле билгесе куела. |
| 5. | 6—7 орфографик, 4—5 пунктуацион хаталы, берничә төзәтүле эшкә | «1» ле билгесе куела. |

Әгәр грамматик бирем бер дә ялгышсыз башкарылса, «5» ле куела. Дүрттән өч өлеше дөрес башкарылмаган грамматик биремгә уңай билге куелмый.

ОТПРАВИТЕЛЬ
МБОУ "Средняя Общеобразовательная Школа №130 Имени Героя Российской Федерации Майора С.А.Ашихмина"
ПОДПИСАНО
ВЛАДЕЛЕЦ СЕРТИФИКАТА
Самаркина Ирина Николаевна
ДОЛЖНОСТЬ
Директор
СЕРТИФИКАТ
00991280801FAAF15BA3173E5BBA8F1E17
ПОДПИСАН
01.12.2024 14:04:28 МСК
ПОДПИСЬ ВЕРНА